КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 29 декабрь г.Казань № 1110

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү инфраструктурасын тәзи торган оешмаларга субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 5 декабрь, 944 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү инфраструктурасын тәзи торган оешмаларга субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү инфраструктурасын тәзи торган оешмаларга субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 5 декабрь, 944 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 13 июль, 512 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына булышлык күрсәтү инфраструктурасын тәзи торган оешмаларга субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

4.3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.3. Субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү планлаштырылган айга кадәр булган айның беренче көненә:

салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиеш салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле бүтән мәҗбүри түләүләр, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри пенсия һәм медицина иминиятләвенә иминият кертемнәре буенча үтәлмәгән йөкләмәләре юк;

Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләр, бюджет инвестицияләрен, шул исәптән бүтән хокукый актлар нигезендә бирелгән, кайтару буенча түләү вакыты чыккан бурычы һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында бүтән түләү вакыты чыккан бурычы юк;

үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында түгел;

чит ил юридик заты, шулай ук устав (җыелма) капиталларында теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы раслый торган дәүләтләр һәм территорияләр исемлегенә кертелгән салым салуның ташламалы салым режимы һәм (яки) финанс операцияләре үткәргәндә мондый юридик затларга мөнәсәбәттә мәгълүматны ачу яки бирү күздә тотылмаган дәүләт яки территория (оффшор зоналар) булган чит ил юридик затлары өлеше гомумән алганда 50 проценттан артып киткән россия юридик заты түгел;

әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән максатларга бүтән норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булып тормый.»;

4.4 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга;

6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«үзәк эшчәнлегенең планлаштырылган нәтиҗәләре турында мәгълүмат;

гариза бирүченең әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында үзәк җитәкчесе имзалаган гариза.»;

7 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гариза биргән айга кадәр булган айның соңгы көненә үзәкнең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына түләнергә тиешле салымнар, җыемнар һәм бүтән мәҗбүри түләүләр түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе юклыгын раслый торган, билгеләнгән тәртиптә таныкланган салым органы белешмәсе;»;

18 пунктта «документларда әлеге Тәртипнең 8 пункты таләпләренә туры килми торган мәгълүматлар булу,» сүзләрен «документларда дөрес булмаган мәгълүматлар булу» сүзләренә алмаштырырга;

22 һәм 23 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Гаризаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча Комиссия түбәндәге карарлар чыгара:

субсидия бирү тәкъдим ителә торган үзәкләрне билгеләү турында;

субсидия бирүдән баш тарту тәкъдим ителә торган үзәкләрне билгеләү турында.

23. Тапшырылган гаризалар әлеге Тәртиптә билгеләнгән таләпләргә туры килгән очракта Министрлык, Комиссия тәкъдимнәрен исәпкә алып, субсидия бирү турында яки субсидия бирүдән баш тарту турында боерык рәвешендә карар кабул итә.»;

түбәндәге эчтәлекле $23^1$ пункт өстәргә:

«$23^1$. Субсидия күләме чыгымнар сметасы нигезендә түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$С = З_{о.т} + З_{о.с} + З_{н.а} + З_{р.м} + З_{к} + З_{у.с} + З_{к.у} + З_{у.с.о} + З_{п.т},$$

монда:

С – бирелә торган субсидия күләме;

$З_{о.т}$ – хезмәткә түләүгә чыгымнар;

$З_{о.с}$ – төп чараларны сатып алуга чыгымнар;

$З_{н.а}$ – матди булмаган активларны сатып алуга чыгымнар (электрон исәпләү машиналары программалары);

$З_{р.м}$ – чыгым материалларын сатып алуга чыгымнар;

$З_{к}$ – командировкаларга чыгымнар;

$З_{у.с}$ – элемтә хезмәтләре күрсәтүләргә чыгымнар;

$З_{к.у}$ – коммуналь хезмәтләр күрсәтүләргә чыгымнар, бүлмәләрне арендалауны кертеп;

$З_{у.с.о}$ – чит оешмалар хезмәт күрсәтүләре өчен түләүгә чыгымнар;

$З_{п.т}$ – башка агымдагы һәм бүтән чыгымнарга тотылган акча.»;

26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«26. Министрлык боерыгы аны раслаган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырыла.»;

27 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«27. Субсидия әлеге Тәртип һәм Министрлык һәм Министрлык тарафыннан субсидия бирү турында уңай карар кабул ителгән үзәк (алга таба – субсидия алучы) арасында төзелгән килешү нигезендә, карар кабул ителгән көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән 10 көн эчендә төзелә.

Килешүдә субсидиянең күләме, аның максатчан билгеләнеше, субсидияне куллану турында хисап бирү тәртибе, формалары һәм вакытлары, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган, әлеге Тәртипнең 5 пунктында күрсәтелгән чыгымнар юнәлешләре буенча чыгымнар исемлеге; субсидиянең хисап финанс елында файдаланмаган өлешен (субсидия калдыкларын) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару тәртибе һәм вакытлары, алынган субсидия исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю, югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән, шулай ук әлеге акчаны бирү максатларына ирешү белән бәйле бүтән операцияләрдән тыш, Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан субсидия алучының субсидия бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүләрне гамәлгә ашыруына субсидия алучының ризалыгы (субсидия алучы дәүләт (муниципаль) унитар предприятие, устав (тупланма) капиталларында гавәми-хокукый берләшмәләр катнашында хуҗалык иптәшлеге һәм җәмгыяте, шулай ук устав (тупланма) капиталларында мондый хуҗалык иптәшлекләре һәм җәмгыятьләре катнашында коммерциячел оешмалар булган очраклардан тыш), субсидия алучының әлеге Тәртип шартларын үтәве турында нигезләмәләр.

Министрлык килешүдә үзәкләр эшчәнлегенең нәтиҗәлек күрсәткечләрен билгели.

Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән үрнәк форма нигезендә төзелә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин